МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 104/о

БОЕРЫК

«09» 07 2020

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эш итүгә бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясындагы 3 өлешенә туры китереп, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының штат расписаниесен раслау турында» 2020 елның 12 февралендәге 25/о номерлы боерыгы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эш итүгә бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эш итүгә бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 17 октябрендәге 174/о номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның «09» 07. №104/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эш итүгә бәйле булган, вазыйфага билгеләнгәндә конкурс уздырылмаска мөмкин Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

эшләр идарәчесе;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы;

финанслау, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

юридик бүлек башлыгы;

мобилизацияле әзерлек, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм яшеренлелек режимы секторы мөдире;

мобилизацияле әзерлек, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм яшеренлелек режимы секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

оештыру эшләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлегенең мәгълүматлаштыру секторы мөдире;

торак хуҗалыгы идарәсенең капиталь ремонт программаларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

торак фонды объектларын эксплуатацияләү һәм торак хуҗалыгы идарәсе территорияләрен төзекләндерү бүлеге башлыгы;

коммуналь хуҗалык идарәсе башлыгы;

коммуналь хуҗалык һәм калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы;

коммуналь хуҗалык идарәсенең коммуналь хуҗалыкта инвестиция программалары бүлеге башлыгы;

коммуналь хуҗалык идарәсенең коммуналь хуҗалык һәм оператив эш бүлеге башлыгы;

төзелеш комплексын үстерү идарәсе башлыгы;

төзелеш комплексын үстерү идарәсенең торак төзелеше бүлеге башлыгы;

төзелеш комплексын үстерү идарәсенең төзелеш комплексында үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы;

төзелеш комплексын үстерү идарәсенең социаль-мәдәни объектлар төзелеше бүлеге башлыгы;

төзелеш технологияләре бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең шәһәр төзү сәясәте бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең территорияләрне планлаштыру һәм төзелеш бүлеге башлыгы;

архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең архитектура һәм проектлау бүлеге башлыгы;

шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тоту бүлеге башлыгы.